СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Наласа авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“31” октябрь 2019 ел** **№96**

**“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл жирлеге составына керүче торак пунктларда халык жыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында”**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа” муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Наласа авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендәге 63 номерлы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында” Нигезләмәне раслау хакында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Наласа авыл җирлеге
башлыгы И.Р.Шакирова

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
Советының
2019 елның 31 октябре
96 номерлы карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында**

**Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә эшләнде.

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Халык җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Халык җыенында торак пунктта даими яки күпчелек вакытта яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия кешеләр катнаша ала.

1.3. Халык җыенында катнашу ихтыярлы һәм ирекле.

1.4. Халык җыенда һәркем шәхсән үзе катнаша һәм бер тавышка ия була.

1.5. Халык җыены халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатыннан үткәрелә.

1.6.Торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия булган халыкның яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә катнашу мөмкинлеге булмаганда, халык җыены Устав нигезендә этаплап уздырыла.

## Халык җыенының вәкаләтләре

1.7. Халык җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүне үз эченә алган күрсәтелгән торак пункт кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә сайлау хокукына ия булган җирлектә яшәүчеләр саны 100 дән артмаганда, җирлекнең вәкаләтле органын оештыру, аның саны һәм вәкаләтләр срогы турындагы мәсьәлә буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

җирлек составына керүче торак пунктта, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориядә, шәһәр округы яисә муниципаль район чикләрендә авылара территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;

халык саны аз булган яки керү кыен булган җирдә урнашкан җирлектә, әгәр авыл җирлегендә халык саны 100 кешедән артмаса, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә, конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында үткәрелергә мөмкин.

**Халык җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.8. Җыен муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Җыенга әзерлек һәм аны үткәрү белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Халык җыенын чакыру тәртибе

Халык җыенын үткәрү инициативасы

2.1. Халык җыенын үткәрү инициативасы торак пунктта түбәндәгеләр карамагында була:

-муниципаль берәмлек башлыгы;

- торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия халык җыенында катнашу хокукы булган 10 кешедән дә ким булмаган төркеме (ягъни Россия Федерациясенең үз гамәлләре өчен җавап бирүче даими яки күбесенчә торак пункт территориясендә яшәүче, яшәү урыны буенча бу торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән гражданнары, шулай ук торак пункт территориясендә даими яисә күбесенчә яшәүче һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукка ия булган чит ил гражданнары).

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы язылу кәгазе (1 нче кушымта) яисә инициатив төркем җыелышының җыен үткәрү инициативасын күрсәтү турында карар кабул ителгән беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә, аларда түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

халык җыенын үткәрүнең тәкъдим ителгән вакыты; халык җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр

гражданинның паспорт сериясе һәм номеры, яшәү урыны, аның имзасы һәм имзасын теркәү датасы.

2.3. Җыенны үткәрү инициативасын хуплау өчен җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, даими яки күпчелек вакытта шунда яшәүче, торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саныннан 5 процент тәшкил итәргә тиеш, ләкин имзалар саны 10 нан ким була алмый.

2.4. Язылу кәгазьләре имзалар җыючы зат тарафыннан таныклау датасын, фамилиясен, атасының исемен, туган датасын, паспорт номерын һәм сериясен, яшәү урынын күрсәтеп таныклана һәм муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

**Халык җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе**

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган халык җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән (2 нче кушымта), ә муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы белән җыела торганы – муниципаль берәмлек башлыгы карары белән (3 нче кушымта) барлык кирәкле документлар кергән көннән 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы аның максатка ярашлы булмавы сәбәпләре буенча халык җыенын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Халык җыенына (халык җыены этапларына) чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәскә тиеш. Халык җыенына чыгарылган мәсьәлә аны күптөрле аңлау мөмкинлеген булдырмау максатыннан чыгып формалаштырылган булырга тиеш, ягъни аңа бары тик бертөсле җавап кына бирергә мөмкин булырлык итеп формалаштырылган булырга тиеш.

2.8. Халык җыенын билгеләү, аны күчерү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә басылып чыга (халыкка җиткерелә).

Халык җыенын үткәрү турында муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында түбәндәгеләр күрсәтелә: халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр; халык җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы - муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе турында мәгълүмат.

2.9. Халык җыенын әзерләү һәм уздыру өчен җаваплы муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе (башкарма-боеру органы), муниципаль берәмлек башлыгы  яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлеген төзи; халык җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; муниципаль берәмлек халкына халык җыены турында массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән хәбәр итә (4 нче кушымта).

Муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы халык җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Халык җыенын этаплап үткәргәндә торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү һәм халык җыенын үткәрү датасын билгеләү территория ягыннан, вакыт буенча, шулай ук башка очраклар буенча булырга мөмкин.

2.9.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе халык җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә (5,6 нчы кушымталар).

2.9.3. Торак пунктта яшәүчеләргә халык җыены (халык җыены этаплары) вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Халык җыенын (халык җыены этапларын) билгеләү турында карар, халык җыенын (халык җыены этапларын) үткәрү вакыты һәм урыны халык җыены (халык җыены этапларын) үткәрелгән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш. Халык җыенының этапларын үткәрү вакыты һәм урыны халык җыенын билгеләү турында карарда күрсәтелә.

2.9.4. Халык җыенын этаплап уздырган очракта, халык җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә этаплап уздырыла. Халык җыены этапларын күчергәндә, җыенны

күчерү турындагы карар җыенны уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча һәм законнар нигезендә җыен үткәрелергә тиешле айлык вакытны исәпкә алып кабул ителергә тиеш.

2.9.5. Җыенның һәр катнашучысы халык җыенына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча әлеге Нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсендә халык җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Халык җыены турындагы Нигезләмә нигезендә, халык җыенын үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Халык җыенын уздыру датасын күчерү турында карар җыен үткәрү билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Халык җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләтләгән зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенга шулай ук катнашырга теләк белдергән хәлиткеч тавыш бирү хокукы булмаган башка гражданнар, җыенда тикшерелә торган мәсьәләләрне хәл итү эшчәнлекләренә кагыла торган предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре килергә мөмкин.

3.3. Сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче кеше әлеге муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан теркәлергә һәм җыенга кертелергә мөмкин.

3.4. Язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) кешенең шәхесен билгеләүче документ раслый (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билет, чит ил гражданины паспорты, Россия

Федерациясендә яшәүгә рөхсәт кәгазе, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт кәгазе һәм башкалар булырга мөмкин.)

3.5. Халык җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда  хокуклы санала. Кворум булмаганда, халык җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта халык җыены халык җыенын үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча үткәрелергә тиеш.

3.6. Халык җыены этаплап уздырылган очракта, барлык уздырылган этаплар йомгаклары буенча тавышларны санап, җыенның аерым этапларында гражданнарның  килүе  нинди булуга карамастан, хокуклы санала, ягъни мондый җыен бер булып кала.

3.7.  Халык җыенында тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турында карар халык җыены тарафыннан кабул ителә (вариант буларак: форма халык җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә).

3.8. Яшерен тавыш бирүне уздырганда халык җыенында катнашу өчен теркәлгән кешегә тавыш бирү өчен бюллетень (7 нче кушымта) бирелә .

3.9. Халык җыенында муниципаль берәмлек башлыгы яисә халык җыенында теркәлгән катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын халык җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.10. Халык җыены сәркатипне һәм Хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны өч кешедән ким була алмый.

Хисап комиссиясенә рәислек итүче керә алмый.

Хисап комиссиясе:

1) халык җыенына килгән халыкның теркәлү дөреслеген, кирәк булган очракта, аларның халык җыенында катнашу хокукларын тикшерә;

2) халык җыенынының кворумын <u>(халык җыены этапларын үткәрүдән тыш) билгели</u>;
3) тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;
4) тавышларны саный һәм тавыш бирүгә йомгак ясый <u>(халык җыены этапларын үткәрүдән тыш)</u>;
5) тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беркетмә төзи (халык җыены нәтиҗәләре буенча);
6) рәискә тавыш бирү нәтиҗәләре белән материаллар тапшыра (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнар исемлеге).

3.11. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, халык җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелә ала. Көн тәртибенә чакырылыш инициаторлары тарафыннан кертелгән сораулар мәҗбүри рәвештә куела. Әлеге мәсьәләләр беренче чиратта карала. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турында карар, аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш биргәндә, кабул ителгән дип санала.

3.12. Халык җыены этаплап үткәрелгәндә шулай ук муниципаль берәмлек башлыгы яисә халык җыенында теркәлгән катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.13. Халык җыены этапларында тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турында карар халык җыены этабында кабул ителә (вариант буларак: форма гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә).

3.14. Халык җыенын этаплап уздырганда, җыен уздыру этапларының һәркайсында Хисап комиссиясе әгъзалары арасыннан гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең кворумны һәм йомгаклау тавышларын санаганда комиссия составында эшләячәк бер әгъзасы сайлана.

3.15. Халык җыены җыенда рәислек итүче тарафыннан ачыла. Халык җыенында рәислек итүче халык җыенын үткәрүне оештыра, тәртипне тәэмин итә, Хисап комиссиясе эшен көйли, куелган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.16. Халык җыенында сәркәтип тарафыннан халык җыенын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны күрсәтелгән беркетмә алып барыла (7 нче кушымта).

3.17. Халык җыенын этаплап уздырганда халык җыенының һәр этабында беркетмәләр (8,9 нчы кушымталар) алып барыла, алар алга таба халык җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча җыенның бер йомгаклау беркетмәсенә (10 нче кушымта), шулай ук Хисап комиссиясе беркетмәләренә (11,12 нче кушымталар), алар шулай ук халык җыенының һәр этабында тавышларны санау нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең бер йомгаклау беркетмәсенә (13 нче кушымта) тутырыла.

3.18. Халык җыенының йомгаклау беркетмәсендә халык җыены этапларының датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, халык җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны турында белешмәләр, халык җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең йомгаклау нәтиҗәләре була. Йомгаклау беркетмәсе җирлек башлыгы кул куя торган халык җыены карарын рәсмиләштерү өчен нигез булып тора.

3.19. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче зат, җыен сәркатибе кул куя һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге теркәлә.

3.20. Халык җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча Хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсендә халык җыены этапларын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, үткәрелгән этаплар саны, халык җыеннарының үткәрелгән этаплары буенча Хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә

яшәүче гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, бирелгән тавышларның һәм каршы тавышларның гомуми саны күрсәтелә.

3.21. Йомгаклау беркетмәсе Хисап комиссиясе рәисе һәм Хисап комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.

## 4. Халык җыены карарлары

4.1. Халык җыены карары сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш биргәндә кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, җирлек уставы белән билгеләнгән вәкаләтләр бүленеше нигезендә, халык җыенында кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга, үзгәртелергә яки суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Халык җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) һәм муниципаль хокукый актлар таләпләре нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрнең туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (әзерләү) кирәк булса, күрсәтелгән актны кабул итү (әзерләү) компетенциясенә керә торган җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты халык җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән соң 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Әлеге вакыт өч айдан артмаска тиеш.

**Халык җыены карарларын үтәү**

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларның үтәлмәве закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
**1 нче кушымта**

ЯЗЫЛУ КӘГАЗЕ

Без, түбәндә кул куючылар,
______________________________________________________________
(халык җыенын үткәрү вакыты)
Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _____________торак пунктында
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
сораулары буенча халык җыены уздыру инициативасын хуплыйбыз.

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы | Яшәү адресы | Паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры | Имза кую датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Язылу кәгазен таныклыйм _____________________________________
имзалар җыючы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне
_______________________________________________________________________
яшәү урыны, паспорт яки аны алмаштыручы документның сериясе һәм номеры

_____________________ (имза һәм дата)

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
**2 нче кушымта**


СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа
авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru


**КАРАР**

**_____________ 20___ел** **№ ____**

**Арча муниципаль районы**
**Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында**
**гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Наласа авыл җирлеге Советы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында ______________________________ адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 20____ ________________ 00 сәгать 00 минутта халык җыены билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:
«Сез 20__ елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _______ торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, ________________________________________________ тыш, ____

сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:_______________________________________________________________
_______________________________________________________________.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге __________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң____ көн эчендә _______________җирлегенең мәгълүмат стендларына һәм рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм ____________________ юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл
җирлеге башлыгы ______________

Татарстан Республикасы<br>Арча муниципаль районы<br>Наласа авыл җирлегендәге<br>торак пунктларда<br>халык җыенын әзерләү<br>һәм уздыру<br>Тәртибенә<br>Знче кушымта


| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НАЛАСИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,<br>Арский муниципальный район, 422018 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НАЛАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br>М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,<br>Арча муниципаль районы, 422018 |

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru


**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгының**
**20___елның __________________ ____номерлы**
**“Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында”**

**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Наласа авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында ______________________________ адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 20____ ________________ 00 сәгать 00 минутта халык җыены билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 20__ елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _______ торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, ________________________________________________ тыш, ____ сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:___________________________________________________.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң____ көн эчендә _______________җирлегенең мәгълүмат стендларына һәм рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм ___________________ юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл
җирлеге башлыгы ______________

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
**4 нче кушымта**

Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында

20___ ел «___» _________________ сайлау хокукына ия яшәүчеләр

ИСЕМЛЕГЕ

| №№ | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яшьтәгеләргә -туган ае, көне) | Яшәү адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Халык җыенында рәислек итүче _________ ______________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Халык җыены сәркатибе _________ _______________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
**5 нче кушымта**


СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru


## КАРАР

**_____________ 20___ел** **№ ____**

### Арча районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Наласа авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында _____________________________адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 20____ _______________ 00 сәгать 00 минутта **халык җыенының беренче этабын** билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында _____________________________ адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 20____ _______________ 00 сәгать 00 минутта **халык җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе _______________________________________________________ билгесе буенча.
1нче этап:______________ _____________________________________
2нче этап:__________________________________________________
(территория ягыннан, вакыт буенча яки башка билге)

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 20__ елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _______________________ торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, _____________________________________________ тыш, ____ сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:_________________________________________________.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң____ көн эчендә ______________җирлегенең мәгълүмат стендларына һәм рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм __________________ юлы белән бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

____________ җирлеге
Совет башлыгы _____________

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
**6 нчы кушымта**

СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.2а, с.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2а йорты,Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы,422016

Тел. (84366)507-35, факс (84366)507-35. E-mail: Sat .Ars@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгының 20___елның _________________ ____номерлы “Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында”**
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Наласа авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында ______________________________ адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 20____ _______________ 00 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында ______________________________ адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 20____ _______________ 00 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе
_____________________________________________________________ билгесе буенча.
(территория ягыннан, вакыт буенча яки башка билге)

1нче этап:_____________________________________________________
2нче этап:____________________________________________________

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 20__ елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _______ торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, _____________________________________________ тыш, ____ сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:________________________________________________.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң____ көн эчендә ______________җирлегенең мәгълүмат стендларына һәм рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм ___________________ юлы белән бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл
җирлеге башлыгы _____________

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
**7 нче кушымта**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ ПРОТОКОЛЫ**

____________________________________________________
(торак пункт исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут № _____

Катнаштылар ____________________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Халык җыенында рәислек итүче ________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Халык җыены сәркатибе ___________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:**

1. ____________________________-____________________________

ФИАИ вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе - кеше
Каршы- кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыенның сәркатибен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булыр?

сәркатип итеп сайлауга ФИО-вазыйфасы тәкъдиме бар.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** халык җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен Хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ___________ ФИАИ һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар: ФИАИ – вазыйфасы, ФИАИ – вазыйфасы.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
**______________________________________________**
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. **______________________________________________**
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
(һ. б. чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**Карар чыгардылар:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше
Карар _______________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
**______________________________________________**
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. **______________________________________________**
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
(һ. б. чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)
**Карар чыгардылар:** (карарның эчтәлеге)
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше
Карар _______________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

Халык җыенында рәислек итүче _________ ________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)
Халык җыены сәркатибе _________ ________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
8 нчы кушымта

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ ПРОТОКОЛЫ**

______________________________________________________

(торак пункт исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут № __1___

Катнаштылар ________________________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Халык җыенында рәислек итүче
______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Халык җыены сәркатибе ________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ БУЛЫП САЙЛАНА**:

ФИАИ-вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе - кеше
Каршы- кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

Рәислек итүче: җыенның сәркатибен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булыр?

сәркатип итеп сайлауга ФИО-вазыйфасы тәкъдиме бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

Рәислек итүче: халык җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп____________ ФИО һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар: ФИАИ – вазыйфасы, ФИАИ – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
(һ. б. чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)
**Карар чыгардылар:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше
Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
(һ.б. чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**Карар чыгардылар**: (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше
Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Рәислек итүче**: йомгаклау карарының нәтиҗәсе халык җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча __________җирлекнең Уставы нигезендә рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка игълан ителәчәк).

Халык җыенында рәислек итүче _________ _________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Халык җыены сәркатибе _________ _________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**Наласа авыл җирлегендәге**
**торак пунктларда**
**халык җыенын әзерләү һәм уздыру**
**Тәртибенә**
**9 нчы кушымта**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫНЫҢ ИКЕНЧЕЭТАБЫ ПРОТОКОЛЫ

________________________________________________________________
(торак пункт исеме)

«___» ____________ 20__ ел   00 сәгать 00 минут                    № 2

Катнаштылар _____________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Халык җыенында рәислек итүче ________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Халык җыены сәркатибе ____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ БУЛЫП САЙЛАНА:**

ФИАИ -вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе - кеше
Каршы- кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

Рәислек итүче: җыенның сәркатибен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булыр?

сәркатип итеп сайлауга ФИО-вазыйфасы тәкъдиме бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

Рәислек итүче: гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ФИО һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар: ФИАИ – вазыйфасы, ФИАИ – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:
________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. _______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
(һ.б. чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)
Карар чыгардылар: (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше
Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:
________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

Чыгыш ясадылар: 1. _______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
(һ. б. чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

Карар чыгардылар: (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Әйе- кеше
Каршы- кеше
Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

Рәислек итүче: йомгаклау карарының нәтиҗәсе халык җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча __________җирлекнең Уставы нигезендә рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка игълан ителәчәк).

Халык җыенында рәислек итүче _________ _________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Халык җыены сәркатибе _________ _________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
10 нче кушымта

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫНЫҢ УЗДЫРЫЛГАН ЭТАПЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ЙОМГАКЛАУ ПРОТОКОЛЫ**

____________________________________
(Татарстан Республикасы торак пункты, муниципаль районы исеме)

«____» __________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут №____

Халык җыенының 20___ елның __________________________ 1 нче номерлы беренче этабы беркетмәсе (рәислек итүче ФИО), 20___ елның __________________________ 2 нче номерлы икенче этабы беркетмәсе (рәислек итүче ФИО) һ.б. нигезендә түбәндәге сорау(лар) буенча этаплап ______________________________________________________________ халык җыеннары уздырылды.

1. Җыенның үткәрелгән этапларының тавыш бирү формасы (ачык яки ябык (яшерен) буенча саны_______
2. Халык җыеннарының этаплаплары беркетмәләре саны ______
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм аның эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны __________;
4. Сайлау хокукына ия һәм халык җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны___________

**Карар бирделәр: (карар эчтәлеге)**
-җыенның этапларына чыгарылган мәсьәләләргә “әйе” дигән тавышларның гомуми саны_________
- җыенның этапларына чыгарылган мәсьәләләргә “каршы” дигән тавышларның гомуми саны_______

**КАРАР: кабул ителде (сәбәпләрен күрсәтеп, кабул ителмәде)**

Рәислек итүче (җирлек башлыгы): ______ _________ _______
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Сәркәтип: _________ ______________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
11 нче кушымта

**Х А Л Ы К  Җ Ы Е Н Ы Н Ы Ң  Б Е Р Е Н Ч Е  Э Т А Б Ы Н Ы Ң  Х И С А П  К О М И С С И Я С Е  П Р О Т О К О Л Ы**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче ___________ торак пунктта тавыш бирү нәтиҗәләре турында

«_____» _______ 2019 ел № 1

____________торак пункты

**Катнаштылар**: Хисап комиссиясе әгъзалары:
1. ФИАИ;
2. ФИАИ;
3. ФИАИ;
һ.б.

Халык җыенында сайлау хокукына ия булган ________кеше катнаша (- тылар).

Халык җыенының беренче этабы көн тәртибе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре :

«_____________________________________________________________________________»

**Әйе_______тавыш**
**Каршы ______тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе ФИАИ
Хисап комиссиясе әгъзалары:
ФИАИ

ФИАИ

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
12 нче кушымта

**Х А Л Ы К  Җ Ы Е Н Ы Н Ы Ң  И К Е Н Ч Е  Э Т А Б Ы Н Ы Ң  Х И С А П К О М И С С И Я С Е  П Р О Т О К О Л Ы**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче ___________ торак пунктта тавыш бирү нәтиҗәләре турында

«_____» ____________ 2019 ел № 2

___________
торак пункты

Катнаштылар: Хисап комиссиясе әгъзалары:
1. ФИАИ;
2. ФИАИ;
3. ФИАИ;
һ.б.

Халык җыенында сайлау хокукына ия булган ________кеше катнаша (- тылар).

Халык җыенының икенче этабы көн тәртибе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре :

«____________________________________________________________________________»

**ӘЙЕ_______тавыш**
**КАРШЫ______тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе ФИАИ
Хисап комиссиясе әгъзалары:
ФИАИ
ФИАИ

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендәге
торак пунктларда
халык җыенын әзерләү һәм уздыру
Тәртибенә
13нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендәге_____________________ халык ыенының беренче, икенче (һ.б.) этаплары буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында ХИСАП КОМИССИЯСЕ ПРОТОКОЛЫ**

«___» ____________ 20__ ел ___________________________т.п.

Халык җыенының беренче, икенче (һ.б.) этаплары нәтиҗәләре
____________________________________________________________
(территориянең исеме
____________________________________________________________
муниципаль берәмлегенең яисә аның өлешенең)
Халык җыены этапларын үткәрү датасы һәм вакыты: ____________ _____________ 20__ ел
Халык җыенында тавыш биргәндә тавышларны санау нәтиҗәсендә:
____________________________________________________________

**Хисап комиссиясе билгеләде:**

1. Халык җыенының үткәрелгән этаплары саны ________________________________________;
2. Халык җыенының үткәрелгән этапларының хисап комиссиясе биргән беркетмәләре саны ______;
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм җыен эшендә катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны__________;
4. Җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны ___________________;
5. Җыенга чыгарылган мәсьәләләргә “Әйе” дигән тавышларның гомуми саны_________;
6. Җыенга чыгарылган мәсьәләләргә “Каршы” дигән тавышларның гомуми саны__________.

**Карар бирделәр:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясының 6 өлеше нигезендә _____________________ мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга, __________________ мәсьәләсе буенча җыен карарын кабул ителгән дип санарга.

Хисап комиссиясе рәисе _____________________ _______________
(фамилиясе, инициаллары) (имза)

Хисап комиссиясе әгъзалары 1. _________________________ _______________
(фамилиясе, инициаллары) (имзалары)

2. _________________________ __________________
(фамилиясе, инициаллары) (имзалары)

Беркетмә төзелде «___» _____________ 20___ ел